КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 21 май г.Казань № 381

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак йортларның газ җайланмасын куллану барышында барлыкка килә торган һәлакәтләрне профилактикалау һәм кисәтү эшләрен оештыру турында

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак йортларның газ җайланмасын эксплуатацияләүгә бәйле булган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан торак йортларның газ җайланмасын куркынычсыз итеп эксплуатацияләүне тәэмин итү буенча чаралар планын (алга таба – План) расларга.

2. Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына, җаваплылыгы чикләнгән «Газпром транс Казань» җәмгыятенә һәм газ җайланмасына техник хезмәт күрсәтү эшләрен башкаручы оешмаларга Планны үтәүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе белән берлектә, профилактика чараларын массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән кешеләр күпләп була торган урыннарда халыкка мәгълүмат бирүнең һәм хәбәр итүнең гомумроссия комплекслы системасы ярдәмендә яктыртуны оештырырга.

4. Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан торак йортларның газ җайланмасын куркынычсыз итеп эксплуатацияләүне тәэмин итү мониторингын гамәлгә ашыруны;

газ җайланмасын кулланганда барлыкка килә торган һәлакәтләрне кисәтү буенча профилактика эшен үткәрү буенча ведомствоара комиссияләр (алга таба – ведомствоара комиссияләр) төзүне; составларына җирле үзидарә органнары, муниципаль торак тикшерүендә тоту вәкилләрен, янгынга каршы федераль хезмәт эшчеләрен һәм хезмәткәрләрен, җаваплылыгы чикләнгән «Газпром трансгаз Казань» җәмгыятенең структур бүлекчәләре, газ җайланмасына хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәткәрләрен, шулай ук күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыручы оешмалар, торак милекчеләре ширкәтләре, торак-төзелеш, торак кооперативлары һәм башка махсуслаштырылган куллану кооперативлары вәкилләрен, күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләрен, торак йортлар милекчеләрен (алардан файдаланучыларны) (алга таба – идарә итүче оешмалар) кертүне;

күпбалалы гаиләләр, ялгыз өлкән һәм социаль имин булмаган гражданнарның яшәү урыннарына аерым игътибар биреп, ведомствоара комиссияләр тарафыннан ел саен газ җайланмасын кулланганда барлыкка килә торган гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә юнәлдерелгән торак йортларның газ җайланмасына профилактик тикшерүләр үткәрелүне тәэмин итүне;

ел саен торак йортларның газ җайланмасына профилактик тикшерүләр үткәрү графикларын эшләүне.

5. Җаваплылыгы чикләнгән «Газпром трансгаз Казань» җәмгыятенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

ведомствоара комиссияләр эшендә катнашуны;

күпфатирлы йортлар урыннарында һәм индивидуаль торак йортларда газ куллану кагыйдәләрен бозулар ачыкланганда, бозучыларның шәхсиләштерелгән мәгълүматларын күрсәтеп, тикшерүләр актларын җирле үзидарә органнарына, идарә итүче оешмаларга, Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә җибәрүне;

төзек булмаган газ җайланмасын эксплуатацияләү фактлары ачыкланганда бозуларны тулысынча бетергәнгә кадәр газ бирүне вакытлыча туктатып торуны һәм бу турында Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә, Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсенә, Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә һәм җирле үзидарә органнарына кичектермәстән хәбәр итүне;

массакүләм мәгълүмат чаралары аша, шулай ук газ бүлүче оешмаларның техник кабинетларында гражданнарга инструктажлар биргәндә һәм абонентлар фатирларында газ җайланмасына техник хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашырганда халык арасында көнкүрештә газ җайланмасын куркынычсыз куллануны пропагандалау эшләрен үткәрүне.

6. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә:

торак йортларның газ җайланмасына техник хезмәт күрсәтүне, аларны ремонтлауны һәм техник диагностикалауны гамәлгә ашыручы оешмаларга мониторинг үткәрергә һәм аларның реестрын алып барырга;

торак йортларда газ җайланмасын куркынычсыз куллану һәм карап тоту кагыйдәләрен бозулар ачыкланганда һәм бозучыларның шәхсиләштерелгән мәгълүматлары күрсәтелгән тикшерүләр актлары Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә кергәндә, ачыкланган бозулар фактларыннан чыгып, бозучыларга карата законнар нигезендә административ йогынты ясау буенча чаралар күрергә;

торак йортларда газ җайланмасын куркынычсыз куллану буенча законнар үтәлешен системалы рәвештә тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга;

кварталга кимендә бер тапкыр газ җайланмасын куркынычсыз итеп эксплуатацияләүне тәэмин итү буенча чараларның үтәлү барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына мәгълүмат бирергә.

7. Идарә итүче оешмаларга торак урыны милекчесе алышыну турында җаваплылыгы чикләнгән «Газпром трансгаз Казань» җәмгыятенең газ бүлүче оешмасына, абонентлар фатирларында газ җайланмасына техник хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр күрсәтүче махсуслаштырылган оешмаларга мәгълүмат бирүне тәкъдим итәргә.

8. Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсенә газны җайга салучы пунктларны тикшерүләрне үткәрүне күздә тотуны тәкъдим итәргә.

9. Җаваплылыгы чикләнгән «Газпром трансгаз Казань» җәмгыятенә магистраль газүткәргечләрнең линия идарәләре тарафыннан газны одорантлаштыруны даими тикшерүдә тотуны һәм башкарылган чаралар турындагы мәгълүматны алга таба Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсенә бирүне тәкъдим итәргә.

10. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына үткәрелә торган профилактика чараларын, шулай ук көнкүрештә куркынычсызлык чараларын массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

11. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин